**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

23.11.2020 № 244пи

Балык Бистәсе штп.

Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирләрендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарына торак һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында

Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 20 апрелендәге “Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында”192 нче номерлы, 2005 елның 7 июнендәге “Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары бирү тәртибен раслау турында” 251 нче номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогында һәм авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр белгечләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары күрсәтүне түбәндәге категория гражданнарга билгеләргә:

- педагогик хезмәткәрләргә, мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына (торак мәйданының социаль нормасы чикләрен чикләмичә), мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсендә эшләүчеләргә – торак, җылылык, ут өчен түләү чыгымнарының 100 проценты күләмендә, торак, җылылык, ут өчен түләү чыгымнарының Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән торак мәйданының социаль нормасы

һәм коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары чикләрендә. Әгәр әлеге

хезмәткәрләр авыл җирендә урнашкан мәгариф учреждениеләрендә, мәдәният һәм социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә 10 елдан да ким эшләмәсәләр һәм шунда яшәсәләр, күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы пенсиягә чыкканнарга сакланып кала.

2.2015 елның 29 декабрендәге "Россия Федерациясенең аерым закон актларына социаль ярдәм чараларын адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычларыннан чыгып бирү һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында" 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чарасы күрсәтүче вәкаләтле орган күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба – СТБДМС) куллану юлы белән һәм ЕГИССО (СТБДМС) операторы билгеләгән форматлар нигезендә бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итүен билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына бюджетны формалаштырганда район бюджетының өстәмә чыгымнарын каплау чыганакларын билгеләргә тәкъдим итәргә.

4. Муниципаль мәгариф учреждениеләре, мәдәният, сәнгать һәм кинематография учреждениеләре җитәкчеләренә торакка һәм коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларын алу мөмкинлеге турында тиешле аңлату эшләре алып барырга.

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2006 елның 22 декабрендәге "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында"233пи номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов